РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«27» февраль, 2026 ел Олы Кайбыч ав. № 36

Кайбыч муниципаль районы Советының 2021 елның 08 ноябрендәге 74 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелек) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2025 елның 12 ноябрендәге 1783 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында»2021 елның 08 ноябрендәге 74 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) торак-коммуналь хуҗалык системасында ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар, региональ операторлар, төзүчеләр белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, күпфатирлы йорт белән турыдан-туры идарә итүне гамәлгә ашыручы күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне ремонтлау эшләрен карап тоту һәм (яисә) үтәү буенча хезмәтләр күрсәтү килешүләре төзелгән затлар, күпфатирлы йортта мондый милекчеләргә торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар тарафыннан мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләр,;»;

1.2. 4.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Алар фикеренчә, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган контрольдә тотыла торган затлар түбәндәгеләргә карата судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

1) контроль (күзәтчелек) чараларын һәм мәҗбүри профилактик визитларны уздыру турында карарлар;

2) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар актлары, күрсәтмәләр;

3) контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар кысаларында контроль (күзәтчелек) орган вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы);

4) контроль объектларын тиешле хәвеф-хәтәр категориясенә кертү турында карарлар;

5) контрольдә тотыла торган затларның гаризалары буенча профилактик визитлар үткәрүдән баш тарту турында карарлар;

6) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган профилактик һәм (яисә) контроль (күзәтчелек) чаралары йомгаклары буенча контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан контрольдә тотыла торган затларга яисә контроль объектларына карата кабул ителә торган башка карарлар.».

2. Әлеге карар, 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган әлеге карарның 1.1пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль
районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин